СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

14.10.2022　　　　с. Майдан　　　　№ 22-116

Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының штат расписаниесен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы "Даими нигездә вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" карары, Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының штат расписаниесен расларга (1-2 кушымта)
2. Югары Ослан районының Мәйдан авыл җирлеге Советының 2005 елның 31 декабрендәге 22 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән законлы көченә керә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　В. В. Михеев

Югары Ослан муниципаль
районының Мәйдан авыл җирлеге
Советының 2022 елның «14»
октябреннән 22-116 карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы
ШТАТ РАСПИСАНИЕСЕ

2022 елның 1 октябренә

| № | Вазифасы | Штат саны Берәмлекләр саны | Акчалата бүләк | Акчалата бүләкләү | Компенсация түләүләре | Айлык фонд |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. | 6. | 7. |
| 1. | Авыл җирлеге башлыгы - Совет рәисе | 1 | 16389 | 9178 | | 28025,00 |
| | Барлыгы: | 1 | 16389 | 9178 | | 28025,00 |

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев

Югары Ослан муниципаль
районынын Мәйдан авыл җирлеге
Советының 2022 елның «14»
октябреннән 22-116 карарына
2 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының
ШТАТ РАСПИСАНИЕСЕ
2022 елның 1 октябренә

| № | Вазифасы | Штат берәмлекләренең саны | Вазыйфаи оклад | Акчалата бүләк | Айлык фонд |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. | 7. |
| 1. | Башкарма комитет секретаре | 1 | 15904 | | 17971,00 |
| | Барлыгы: | 1 | 15904 | | 17971,00 |

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев